**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 ноябрь № 833

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт

оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнә.»;

4.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

6 бүлекнең 6.1 пунктындагы бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$H_f$ – хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгы кысаларында Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең гамәлдәге эш сәгатьләре саны;

«$H_N$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең төп эш хакына (төп окладка) сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгы).»;

9 бүлекнең 34 таблицасында:

1 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләре»;

2 пунктта «өлкән инвалидлар, шул исәптән сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль-тернәкләндерү оешмалары,» сүзләрен «инвалидларны тернәкләндерү үзәге, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль тернәкләндерү үзәге,» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексլы үзәкләре, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләре»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

11.1 пунктның 2 графасында «Барлык вазыйфалар» сүзләреннән соң «(әлеге таблицаның 11.2 пунктында күрсәтелгән вазыйфалардан тыш» сүзләрен өстәргә;

әлеге кушымтага түбәндәге эчтәлекле 11.2 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «11.2. | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | 25»; |

12.1 пунктта «медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, педагогик хезмәткәрләр» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты көче Нигезләмәгә 1 нче кушымтага үзгәрешләр керткән өлешендә 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\833.docx